# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Сатудан салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә әлеге Закон белән Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле сатудан салым билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

**1 статья.** Салым түләүчеләр

1. Сатудан салым түләүчеләр булып (алга таба – салым түләүчеләр) түбәндәгеләр таныла:

1) оешмалар;

2) индивидуаль эшкуарлар.

2. Әгәр бу статьяда күрсәтелгән оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар товарларын (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) Татарстан Республикасы территориясендә реализацияләсәләр, алар салым түләүчеләр булып таныла.

**2 статья.** Салым салу объекты

Татарстан Республикасы территориясендә физик затларга товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләү буенча башкарылган гамәлләр салым салу объекты булып таныла.

Товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) реализацияләү акчалата исәп-хисап ясап, шулай ук исәп-хисап яки кредит банк карталарын файдаланып башкарылган очракта, мондый реализация гамәлләре салым салу объекты булып таныла.

**3 статья.** Салым салынырга тиеш булмаган (салым салудан азат ителә торган) гамәлләр

1. Физик затларга түбәндәге товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләү буенча башкарыла торган гамәлләргә салым салынырга тиеш түгел (салым салудан азат ителәләр):

икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләрен, сөт һәм сөт продуктларын, үсемлек майларын, маргаринны, онны, йомырканы, ярмаларны, шикәрне, тозны, бәрәңгене, балалар һәм диабетик туклану продуктларын;

балалар өс киемен һәм аяк киемен;

даруларны, протез-ортопедия әйберләрен;

торак-коммуналь хезмәтләрен, халыкка торак биналарны наемга бирү буенча хезмәт күрсәтүләрне, шулай ук тулай торакларда тору урыны бирү буенча хезмәт күрсәтүләрне;

биналарны, корылмаларны, җир кишәрлекләрен һәм күчемсез мөлкәткә караган башка объектларны, шулай ук кыйммәтле кәгазьләрне;

санатория-курорт һәм савыктыру учреждениеләренә, ял итү учреждениеләренә инвалидларга сатып бирелә торган юлламаларны (курсовкаларны);

уку-укыту, укыту-җитештерү, фәнни яисә тәрбияви процессларга бәйле һәм белем бирү учреждениеләре җитештерә торган товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне);

уку-укыту һәм фәнни китап продукциясен;

реклама яки эротик характердагы вакытлы матбугат басмаларыннан гайре, вакытлы матбугат басмаларын;

мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм оешмалары (театрлар, кинотеатрлар, концерт оешмалары һәм коллективлары, клуб учреждениеләре, шул исәптән авыл клублары, китапханәләр, цирклар, лекторийлар, планетарийлар, мәдәният һәм ял парклары, ботаника бакчалары, зоопарклар) тарафыннан театр-тамаша, мәдәни-агарту чаралары, шул исәптән керү билетлары һәм абонементлар сату эшләре башкарылганда күрсәтелә торган мәдәни һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләрне;

балаларны мәктәпкәчә учреждениеләрдә тоту, авыруларны һәм картларны карау буенча хезмәт күрсәтүләрне;

муниципаль берәмлекләрнең гомуми файдаланыштагы транспортында (таксидан гайре) пассажирлар йөртү, шулай ук пассажирларны шәһәр яны

диңгез, елга, тимер юл һәм автомобиль транспортында йөртү буенча хезмәт күрсәтүләрне;

кредит оешмалары, иминиләштерүчеләр, дәүләткә карамаган пенсия фондлары, кыйммәтле кәгазьләр базарында һөнәри катнашучыларның лицензияләнергә тиешле эшчәнлекләре кысаларында күрсәтелүче хезмәтләрен, шулай ук адвокатлар коллегиясе күрсәтә торган хезмәтләрне;

күмү бюроларының, зиратларның һәм крематорийларның ритуаль хезмәт күрсәтүләрен, дини оешмалар тарафыннан йолалар һәм тантаналар үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләрне;

дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарының һәм җирле үзидарә органнарының пошлина һәм җыемнарның тиешле төрләре алына торган хезмәт күрсәтүләрен.

2. Әгәр әлеге статья нигезендә салым түләүче салым салынырга тиешле гамәлләрне дә, салым салынмаска тиешле (салым салудан азат ителә торган) гамәлләрне дә башкарса, салым түләүче мондый гамәлләрнең исәбен аерым-аерым алып барырга тиеш.

**4 статья.** Салым базасы

Салым базасы реализацияләнгән товарларның (эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең) өстәлгән бәягә салымны һәм акцизларны (акцизлар алынырга тиешле товарлар өчен) исәпкә алып кулланыла торган хактан (тарифлардан) чыгып исәпләнгән салым кертелмәгән бәясе буларак билгеләнә.

**5 статья.** Салым чоры

Салым чоры календарь ай буларак билгеләнә.

**6 статья.** Салым ставкасы

Сатудан салым ставкасы 5 процент күләмендә билгеләнә.

**7 статья.** Салымны исәпләү тәртибе

1. Салым суммасы салым базасының салым ставкасына туры килә торган процент өлеше буларак исәпләнә.

Салым суммасы салым түләүче тарафыннан сатып алучыга (заказчыга, жибәрүчегә) түләр өчен куела торган товар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) бәясенә кертелә.

2. Салым Россия Федерациясенең Салым кодексы нигезендә салым салынырга тиешле товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләү гамәлләре башкарыла торган урында түләнергә тиеш.

3. Әгәр комиссия шартнамәсе (йөкләү шартнамәсе, агентлык шартнамәсе) шартлары нигезендә сатып алучыларга товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) фактта реализацияләү комиссионер (ышанычлы зат, агент) тарафыннан башкарылса һәм реализацияләнгән товар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) өчен алынган акча комиссионер (ышанычлы зат, агент) кассасына (исәп-хисап счетына) керсә, салым түләү һәм аны бюджетка күчерү вазыйфасы мондый очракта салым агенты булып танылa торган комиссионерга (ышанычлы затка, агентка) йөкләнә. Бу вакытта салым суммасы товарның (эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең) комиссионерга (ышанычлы затка, агентка) бирелә торган бүләкләү акчасын да үз эченә ала торган тулы бәясеннән чыгып исәпләнә. Комитент (ышанып тапшыручы, принципал) комиссионердан (ышанычлы заттан, агенттан) акчалата керем алганда, әгәр комиссионер (ышанып тапшыручы, агент) салымны түләгән булса, салым түләми.

Әгәр комиссия шартнамәсе (йөкләү шартнамәсе, агентлык шартнамәсе) шартлары нигезендә сатып алучыларга товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) фактта реализацияләү комиссионер (ышанычлы зат, агент) тарафыннан башкарыла, ә реализацияләнгән товар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) өчен алынган акча комитент (ышанып тапшыручы, принципал) кассасына (исәп- хисап счетына) керсә, салым комитент (ышанып тапшыручы, принципал) тарафыннан бюджетка түләнә. Бу вакытта салым суммасы, товарның тулы бәясеннән чыгып, комитент (ышанып тапшыручы, принципал) тарафыннан исәпләнелә.

4. Реализацияләнгән товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) өчен банклардагы счетларга акчалар керү көне яки акчалата төшемнең кассага керү коне, яисә товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алучыга тапшырган көн салым салу объекты буларак танылa торган товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) реализацияләү гамәлләрен башкару датасы булып санала.

**8 статья.** Салымны оешманың аерымланган бүлекчәләре урнашкан җирдә исәпләү һәм түләү үзенчәлекләре

Товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) үзенең әлеге оешма урнашкан җирдән читтәге аерымланган бүлекчәләре аша реализацияләү эшләрен гамәлгә ашыручы оешма салымны товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) реализацияләү гамәлләре башкарыла торган район (шәһәр) территориясендә әлеге аерымланган бүлекчәләр аша реализацияләнә торган товарлар (эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр) бәясеннән чыгып түли.

**9 статья.** Салым түләү тәртибе һәм вакытлары

1. Сатудан салым түләүләр салым түләүчеләр тарафыннан физик затларга узган салым чоры эчендә товарларны (эш башкаруларны, хезмәт күрсәтүләрне) тиешле реализацияләнүдән чыгып, узган салым чорыннан соң килүче айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, һәр салым чоры йомгаклары буенча башкарыла.

2. Салым түләүчеләр үзләре исәптә торган урындагы салым органнарына, узган салым чорыннан соң килүче айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, кушымтада күрсәтелгән рәвештәге тиешле салым декларациясен кертергә тиеш.

**10 статья.** Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе турында

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай үткәч, әмма сатуларга салым буенча чираттагы салым чорының 1 числосына кадәр үз көченә керә. Әлеге Закон гамәлгә кергәч, «Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында» Россия Федерациясе Законының 20 статьясының 1 пунктындагы «г» пунктчасында, шулай ук 21 статьясының 1 пунктындагы «г», «е», «и», «к», «л», «м», «н», «о», «п», «р», «с», «т», «у», «ф», «х», «ц» пунктчаларында каралган салымнар алынмый.

146

2. Әлеге Закон гамәлгә кертелгән көннән «Сатудан салым турында» 1999 елның 27 маендагы 2194 номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 7) үз көчен югалтуын танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары
№ 1287